**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЕКАТЕРИНИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
423196, РТ Новошешминский район с. Сл.Екатерининская, ул. Приовражная д. 9.

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЕКАТЕРИНА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
423196, РТ Яңа Чишмә районы ,Екатерина Бестэсе авылы, Приовражная урамы, 9

Тел.(8-4348) 3-67-36, факс:(8-4348) 3-67-36.Ekat.Nsm@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2021 елның 30 нчы июне № 15

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Екатерина авыл җирлеге башкарма комитетының 2018 елның 7 ноябрьда кабул ителгән «Социаль наем шартнамәсе буенча бирелә торган торак урыннарны алмаштыру документларын рәсмиләштерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 25 нче номерлы карары үз көчен югалткан дип санау хакында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру максатларында, «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2010 елның 2 ноябрендәге 880 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына таянып, Татарстан Республикасының Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «Яңа Чишмә муниципаль районы җирле үзидарә органнары тарафыннан күрсәтелә торган муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен һәм муниципаль хезмәтләрнең реестрын алып бару тәртибе турындагы нигезләмәне раслау турында»гы 21.02.2011 ел, №46 карары нигезендә (2011 елның 13 декабрендәге 493 номерлы, 07.06.2012 елдагы 228 номерлы карарга үзгәрешләр кертүне исәпкә алып), Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Екатерина авыл җирлеге башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Екатерина авыл җирлеге башкарма комитетының 2018 елның 7 ноябрьда кабул ителгән «Социаль наем шартнамәсе буенча бирелә торган торак урыннарны алмаштыру документларын рәсмиләштерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 25 нче номерлы карары үз көчен югалткан дип санарга.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталының рәсми сайтында “Интернет” мәгълүмат - телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru, Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында http://novosheshminsk.tatarstan.ru/. бастырып чыгарырга (халыкка игълан итәргә).
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Екатерина авыл җирлеге башлыгы А.А.Хорьков